БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«29» 09 2020 ел. № 288

«Балтач муниципаль районында аренда түләүләрен түләүне кичектереп тору өлешендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм чаралары турында» 2020 елның 25 маендагы 185 номерлы Балтач район башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

2020 елның 14 августындагы 1536-р номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе нигезендә Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. «Балтач муниципаль районында аренда түләүләрен түләүне кичектереп тору өлешендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм чаралары турында» 2020 елның 25 маендагы 185 номерлы Балтач район башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктта:

«а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән арендага алучылар - кече һәм урта эшкуарлык субъектлары, коммерциягә карамаган оешмалар - иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтүчеләр реестрына кертелгән социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар - иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтүчеләр мөрәҗәгатеннән соң 7 эш көне дәвамында 2020 елның 1 апреленнән 2020 елның 1 октябренә кадәр түбәндәге шартларда аренда түләүләрен кичектерүне күздә тота торган Татарстан Республикасы дәүләт казнасын (шул исәптән җир кишәрлекләрен) тәшкил итүче дәүләт мөлкәтен арендалау шартнамәләре буенча өстәмә килешүләр төзү:

аренда түләве буенча бурыч 2021 елның 1 гыйнварыннан да иртәрәк түләнергә тиеш түгел, әмма 2023 елның 1 гыйнварыннан да соңга калмыйча, этаплап, айга бер тапкырдан да артмыйча, аренда шартнамәсе буенча айлык аренда түләве күләменнән артмый торган тигез түләүләр белән түләнергә тиеш;

кичектерүгә бәйле рәвештә, чит акчалардан файдаланган өчен штрафлар, процентлар яки арендага алучы тарафыннан аренда түләвен кертү тәртибен һәм вакытын сакламау (шул исәптән мондый чаралар аренда

шартнамәсендә каралган очракларда) белән бәйле рәвештә башка җаваплылык чаралары кулланылмый;

кичектереп тору белән бәйле рәвештә арендага алучы тарафыннан түләнергә тиешле өстәмә түләүләрне билгеләү рөхсәт ителми;

аренда шартнамәсен вакытыннан алда өзгәндә, аренда түләве буенча бурыч берьюлы түләнә;»;

«б» пунктчасында «кече һәм урта эшкуарлык субъектлары» сүзләреннән соң «социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар» сүзләрен өстәргә»;

1.2. 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Аренда түләүләрен кичектереп тору Татарстан Республикасы территориясендә гадәттән тыш хәл режимы кертелгән көнгә Татарстан Республикасы дәүләт казнасын (шул исәптән җир кишәрлекләрен) тәшкил итүче дәүләт мөлкәтен арендалау шартнамәләре буенча узган чор өчен аренда түләүләрен түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмаган кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына яисә коммерциягә карамаган оешмалар - иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүчеләр реестрына кертелгән социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар - иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүчеләргә бирелә дип билгеләргә.»;

1.3. 2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Башкарма хакимият органнарына, шулай ук алар карамагындагы дәүләт предприятиеләренә һәм дәүләт учреждениеләренә, 2020 елның 1 апреленә кадәр төзелгән дәүләт мөлкәтен арендалау шартнамәләре буенча һәм алар буенча арендага алучылар булып торган «Яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәсендә килеп туган хәлнең начараюы шартларында зыян күргән Россия икътисадының тармаклары исемлеген раслау турында» 2020 елның 3 апрелендәге 434 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәсендә килеп туган хәлнең начараюы шартларында зыян күргән Россия икътисадының тармаклары исемлеге буенча бер яки берничә тармакта эшчәнлек алып баручы кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектлары яисә коммерциягә карамаган оешмалар - иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүчеләр реестрына кертелгән социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар - иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүчеләргә «Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору шартлары турында» 2020 елның 22 апрелендәге 314 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә 2020 елда каралган аренда түләвен кичектерүне тәэмин итәргә.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми http://www.baltasi.tatarstan.ru сайтында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырырга: http://www.pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе                                                                                    А.Ф. Хәйретдинов